**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Мөслим муниципаль районы**
**Метрәй авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Митряевского сельского**
**поселения Муслюмовского**
**муниципального района**

*423970 РТ. Муслюмовский район, с.Митряево ул. Кооперативная дом 52*
Mitr.Mus@tatar.ru тел.*8(8-5556)3-25-38*
ИНН 1629001096,КПП 162901001,ОГРН 1021605558424,ОКАТО 92242835000

Метрәй авылы

« 21 » март 2019ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 2

КАРАР №2

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 49 статьясындагы 8 пункты нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне гадәттән тыш хәлләрдән кисәтү һәм яклау максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елгы язгы ташу чорына Метрәй авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау планын №1 кушымта итеп расларга.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге икътисад объектларын гадәттән тыш хәлләрдән кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиягә тәкъдим итәргә:

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын кисәтү комиссиясе утырышларында язгы ташу суларын авариясез уздырып җибәрүне тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
– язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә реакция ясау һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын аныклауны оештырырга. Көч һәм чаралар турында мәгълүматларны җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен контрольдә тотуны оештыру, язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
- язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән халыкны һәм территорияләрне саклау буенча чаралар үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Мөслим муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенәгә « Ташу» планын тормышка ашыру турында мәгълүматларны 23.03.2019г елга кадәр тапшырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстендә калдырам

Авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Ф.Я.Гизтдинов

Мөслим муниципаль районы
Метрәй авыл җирлеге
Советының
21.03.2019 ел, 2 нче санлы
карарына 1нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегендә**
**2019 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм территорияләрне яклау буенча**
**чаралар ПЛАНЫ**

| **№ п\п** | **Чаралар** | **Башкару вакыты** | **Башкаручы** |
|---|---|---|---|
| 1. | 2019 елгы язгы ташуга әзерлек мәсьәләсе буенча утырыш үткәрү. | 22.03.2019 ел | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Авыл җирлеге территориясендә язгы ташу күренешләре белән бәйле гадәттән тыш хәләрне булдырмау, нәтиҗәләрен бетерү буенча оператив планны корректировкалау | 22.03.2019 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3. | Юлсызлык вакытында юллар, керү юллары торышына контрольне оештыру | Ташу чорында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 4. | Метрәй авыл җирлеге территориясендә урнашкан оешма, учреждение җитәкчеләре белән гадәттән тыш хәл килеп чыканда кулланыла торган кагыйдәләр турында әңгәмә үткәрергә | 25.03.2019 кадәр | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5. | Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, шәхси әңгәмәләр, халык җыеннары үткәрү юлы белән халыкка җиткерү. Метрәй авыл җирлеге сайтында, стендларда, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда кулланылучы кагыйдәләр турында мәгълүмат урнаштыру. | Ташу чоры башланганчы | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 6. | Су басу куркынычы булган зонага кергән торак биналардан һәм корылмалардан ташу суларын бору буенча эш оештыру | Ташу чорында | Башкарма комитет җитәкчесе, шәхси йорт хуҗалары |
| 7. | язгы ташу чорында зыян күрүчеләргә медицина ярдәмен күрсәтүне буенча әзерлек эшләрен үткәрү. | Ташу чорында | Башкарма комитет җитәкчесе ФАП хезмәткәрләре(килешү буенча) |